Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлегенең Иске Салавыч авылында

ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«23» март, 2024 ел. №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 нче маддәсе нигезендә Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлегенең Иске Салавыч торак пунктында халык җыены карар бирде:

1. 2023 елның 7 ноябрендә Татарстан Республикасының Балтач муниципаль районының Салавыч авыл җирлегенең Иске Салавыч торак пунктында гражданнар җыелышы №2 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 2 нче пункт түбәндәгечә расларга:

«2. Алынган акчаны түбәндәге эшне башкарып җирле әһәмияттәге проблемаларны чишү өчен кулланырга:

- һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү: (Иске Салавыч торак пунктында Бөек Ватан сугышы ветераннары һәйкәлен төзекләндерү;

- торак пункт территориясен төзекләндерү: Иске Салавыч торак пункты территориясен төзекләндерү; Иске Салавыч торак пункты территориясен чистарту һәм җыештыру;

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспартировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау: су белән тәэмин итү проекты

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,<br>Татарстан Республикасы<br>Балтач муниципаль районы<br>Салавыч авыл җирлеге башлыгы Р.К.Латипов